**Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«18» апрель 2025 ел. № 20

Түбән Үрәс авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Түбән Үрәс авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 бүлектәге 4.23 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контроль чара, шулай ук Контроль төре турында Федераль законда каралган башка чаралар акты рәсмиләштерелгәннән соң, контрольдә тотылучы затка ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең уңайлы вакытын күрсәтеп, күрсәтмә бирергә, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы В.Г. Сәфәров